# A LIFE DEVOTED TO SCIENCE

**Iskander Engelevich Yarmakeyev,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation.
ermakeev@mail.ru.



**GALIMDZHAN NIGMATI (full name – GALIMDZHAN AMIRZHANOVICH NIGMATULLIN) [14(26).07/1897 – 4/11/1941]** was a Tatar expert in Literary Studies and a literary critic. He was born in the village of Urdyak, which is currently situated in the Republic of Bashkortostan. Galimdzhan studied at the Communist University of Toilers of the East (1921–1922) and Moscow University of Journalism (1923). Until 1926 he worked as an instructor in the publishing department of the Central Committee of the All-Russian Bolsheviks Communist Party. In 1926–1929 he was an editor of the newspaper "Kyzyl Tatarstan" ("Red Tatariya"). From 1928 he worked at Kazan State Pedagogical Institute (in 1933 – as an Associate Professor in the Tatar Language and Literature Department, in 1934 –1937 – as the Head of this Department, in 1935 as a Professor). In 1930– 1932 he was an editor of the journal "Yanalif". Besides, since 1934, he was a member of the Writers' Union of the USSR. Galimdzhan Nigmati was one of the founders of the cultural- historical school in Tatar literary criticism (the period of the 1920s and early 1930s). He is the author of works on

**ГАЛИМҖАН ӘМИРҖАН УЛЫ НИГЪМӘТИ [14(26).07.1897 – 04.11.1941]** – күренекле әдәбият галиме, тәнкыйтьче. Хәзерге Башкортстан Республикасының Чишмә районы Үдрәкбаш (Өйдерәкбаш) авылында крестьян гаиләсендә туа.

1921-1922 елларда Шәрык хезмәт ияләренең коммунистик университетында, 1923тә Мәскәү журналистика институтында укый. 1926 елга кадәр ВКП (б) ҮКы матбугат бүлегендә инструктор була.

«Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасының баш мөхәррире (1926-1929). 1928 елдан Казан дәүләт педагогия институтында педагогик эшчәнлектә. 1933 елда татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, ә 1934 елдан кафедра мөдире, профессор (1935 елдан) вазифаларын башкара. 1930—1932 елларда «Яңалиф» журналының мөхәррире. СССР Язучылар берлеге әгъзасы (1934). 1920 - 1930 елларның беренче яртысында татар әдәбият белемендә формалашкан культура-тарих мәктәбенә нигез салучы. Татар әдәбияты теориясе һәм тарихы, татар әдәбият белеме методоло-

**ГАЛИМДЖАН НИГМАТИ (настоящее имя и фамилия – ГАЛИМДЖАН АМИРЖАНОВИЧ НИГМАТУЛЛИН) [14(26).07.1897 – 4.11.1941]** – татарский литературовед, литературный критик. Родился в с. Урдяк (ныне находится в Республике Башкортостан). Учился в Коммунистическом университете трудящихся Востока (1921–1922), в Московском институте журналистики (1923). До 1926 г. был инструктором отдела печати ЦК ВКП(б). В 1926–1929 гг. редактор газеты «Кызыл Татарстан» («Красная Татария»). С 1928 г. на педагогической работе в Казанском государственном педагогическом институте (в 1933 г. – доцент кафедры татарского языка и татарской литературы, в 1934–1937 гг. – зав. кафедрой татарского языка и татарской литературы, с 1935 г. профессор). В 1930–1932 гг. редактор журнала «Яңалиф».

Один из основоположников культурно-исторической школы в татарском литературоведении 1920 – первой половины1930-х гг. Автор трудов по истории и теоретическим проблемам татарской литературы: «В мире литературы»

historical and theoretical issues of Tatar literature: “In the Realm of Literature” (1925), “Our Literature in the Years of the Revolution” (1929), “Literature and Life” (1931), etc. Galimdzhan Nigmati was unreasonably purged and rehabilitated posthumously.

гиясе, әдәби тәнкыйте тармакларыннан монографик хезмәтләр авторы: “Әдәбият мәйданында” (1925), “Революция елларында әдәбиятыбыз” (1929), “Әдәбият һәм тормыш: Әдәбият фәне мәсьәләләре, тәнкыйть” (1931) һ.б. лар.

Шәхес культы корбаны, реабилитацияләнгән.

(1925), «Наша литература в годы революции» (1929), «Литература и жизнь» (1931) и др. Был необоснованно репрессирован, реабилитирован посмертно.

On July 26, 2017, the academia and arts communities celebrated the 120th birth anniversary of Galimdzhan Nigmati, a famous theorist of literature, a publicist, critic, and educator. During his brief life he contributed a lot to the development of the history and theory of Tatar literature, literary criticism, to the spiritual life and scientific thought of the Tatars. He is known to be an outstanding public figure and a distinguished scholar who had a considerable influence on the development of the literary process in Tatarstan.

Galimdzhan Nigmati was born into a family of peasants on July 26, 1897, in the village of Udryakbash, Safar district, the region of Ufa (currently it is the village of Chishma in the Republic of Bashkortostan). When Galimdzhan was two years old his family moved to the city of Ufa.

Despite the fact that his father Amirdzhan was just an ordinary laborer and his life was hard enough, he tried to provide for his son’s good education. So after his primary education, Galimdzhan was sent to ‘a progressive madrasa’, called “Galiya”. In the Turkic-Tatar world the school was known as the one providing good secular and religious education. As the family of Galimdzhan Nigmati could not afford the fees, madrasa principal, Zyya Kamali, offered Galimdzhan to tutor children from wealthy families. Thus, at the age of 17–18, the young man began teaching literature to shakirds (students) of the madrasa.

Galimdzhan Nigmati was very much influenced by Galimdzhan Ibragimov, an outstanding writer, scholar and educator, who was teaching Tatar Literature at “Galiya” from the autumn of 1915 till the February Revolution in 1917. He also played a great role in the development of Galimdzhan Nigmati's literary worldview. His pedagogy was based on the idea of developing his students’ ability to think independently and creatively. Galimdzhan Nigmati began to write poems and plays while in madrasa. At that time he released a handwritten literary and social magazine first called “Ai”, which was later on renamed “Parlak”. Khasan Tufan, Shayekhzada Babich, Saifi Kudash, Chenakai, and Shamun Fidai published their works there.

“Since the autumn of 1918, he had been working as a ‘literature’ officer in the newspaper “Kyzyl Yau” published in Tatar in Ufa by the political department of the Fifth Red Army of the Eastern Front. < > In 1921, G. Nigmati arrived in Moscow for further training and completed a one-year course at the Communist University of Toilers of the East” [Dautov, Rakhmani, 2009, p. 197]. His teachers were A.V. Lunacharskiy, L. B. Krasin, historician M. N. Pokrovskiy, orientalists A. A. Guber, I. M. Reysner, and B. Z. Shumyatskiy. Safa Borhan, Yarly Karim, Makhmud Maksud, Fatikh Saify-Kazanly, Naki Isanbet, Latif Gumerov, Iskhak Yenikeyev were in the same year with G.Nigmati. To continue his creative activities at the university, G. Nigmati, together with Kh. Ishbulatov and M. Maksud, organized a literary society and began publishing a hectographic literary journal. The famous poet Khadi Taktash is known to have published his works there, too.

In September, 1922, G. Nigmati was enrolled at the Moscow State Institute of Journalism. His fellow students were Gubaidulld Kushayev, Shakir Ramzi and future employees of editorial offices of Kazan newspapers and journals. The academically profound lectures on the history of literature delivered by V. L. L’vov-Rogachevskiy and P. S. Kogan, the lectures of N. K. Ivanov-Gramen and F. G. Muskatblit on the theory of journalism made a great impression on the students and helped them to determine the trajectory of their future research.

In 1923, the Central Executive Committee of the All-Russian Bolsheviks Communist Party, where G. Nigmati worked in the Tatar-Bashkir Department since October 15, 1923, established the ‘Political Department for National Journalism’. He was in charge of Tatar-Bashkir RSFSR publications sent from Turkmenistan, Kyrgyzstan, Tatarstan, Bashkortostan, the Crimea and other autonomous republics. At the same time, newspapers and journals began publishing not only the journalistic articles of G. Nigmati but also his literary research.

In 1925, he contributed his work to "Adabi Maidan", the journal famous for its studies of literary phenomena and its cultural and aesthetic attitudes [Nigmati, 1925]. "Having studied in detail the issue of literary genesis in his first theoretical work published in "Adabi Maidan" (Moscow, 1925), Nigmati found that literature is a socio-aesthetic subject, a phenomenon that is created in connection with the process of work, with life and practical needs of people" [Galiyeva, 2002: 40].

G. Nigmati developed his own style, based on a close relationship between the ethnic character of literature and its universal nature. Consequently, the scholar turned his attention from studying the panorama of the world art to researching the phenomenon of national literature, to exploring the works of G. Ibragimov, G. Tukay, Dardmend, S. Ramiyev, and Kh. Taktash.

In November, 1926, G. Nigmati arrived in Kazan and was appointed editor of Kazan quality newspaper "Kyzyl Tatrstan" and the journal "Yanalif". At the same time, he worked as the editor-in-chief of the Tatar State Publishing house and was involved in organization of the Union of Tatarstan Writers. In May, 1928, G. Nigmati. F. Saifi, G. Tolymbay, G. Kutuy, and K.Tinchurin became members of the Union Board.

When working as the editor-in-chief of the Publishing house, G. Nigmati invested much effort in the study and preservation of Tatar literature. He was one of those who initiated the publication of Dardmend's selected works and wrote a foreword to it. A characteristic feature of G. Nigmati's personality was his care for young Tatar writers and poets. In the literary world his first priority was originality and breadth of representation as well as research in the field of artistic techniques. In 1929, G. Nigmati published the first collection of poems by Khadi Taktash with his introductory article. He acquainted public with the innovative poet Khadi Taktash, helped Ibrakhim Gazi, Mirsay Amir and others to make their first steps in the world of literature and to find their own paths in life.

Later, in 1931, his second fundamental work "Literature and Life: Issues of Literary Studies and Criticism" was published. G. Nigmati thought that scientific research into Tatar literature and verbal art was one of the most important and timely issues of literary criticism, and this work of his was an experience of literary research within the framework of the Cultural-Historical School [Nignati, 1931].

In the autumn of 1929, started another important stage in G. Nigmati's life: he began delivering lectures on the History of Tatar Literature of the 20th century (works created before 1917) in the East Pedagogical Institute (since 1934 – the Kazan State Pedagogical Institute), in 1935 he received a professorial degree.

G. Nigmati's work at this higher school, his pedagogical and methodological activities revived the literary society. It was then that Sibgat Khakim stepped into the world of literature, Khasan Khairy, Mukhammat Gainullin, Khatip Gusman, Khamit Yarmi, Afzal Kudash and dozens of other philologists developed their analytical flair and power of thought.

During those years Galimdzhan Nigmati proved to be a talented scholar and literary expert, as an author of the works on the history and theory of Tatar literature and became a well-known critic. He successfully worked in the field of literary criticism studying the oeuvre of writers before 1917 (G. Ibragimov, G. Tukay, M. Gafuri, Dardmend and others): "In the 1920s and 1930s, G. Nigmati started writing the biography of Tukay and discovered a number of new facts. He showed the great role that Russian and European poets played in the development of Tukay's poetic skill. < > He focused on such features of the poet's creative work as his increasingly critical attitude to the social environment, the close connection between his work and reality, his rise to a higher level from the point of realism, etc." [Gilyazov, 2016: 486–487]. Within a short period of time he created fundamental works on the methodology of literature and art; despite the inconsistency and complexity of his time, G. Nigmati managed to publish a series of articles on the works of Soviet writers (K. Nadzhmy, G. Tolymbay, Kh. Tufan and others) [Nigmati, 1934]. The scholar also distinguished himself as an expert in Russian (classical and modern) and Western (classical) Literature. He wrote articles devoted to the oeuvre of L. N. Tolstoy, A. M. Gor'kiy, A. P. Chekhov and others. According to the researchers of his works, the prominent feature of G. Nigmati's scientific activity was his desire to bring out the characteristics of fiction and art through a comprehensive study. G. Nigmati realized the great responsibility that he was taking when, in the 1930s, he was appointed head of the literary council of the Tatar State Academic Theater.

At the end of the terrible and dangerous 1930s, G. Nigmati's life and creative work came to a tragic and untimely end. This talented scholar, an expert in literature, a principal critic and publicist, as dozens of other famous Tatar representatives of science and culture, was accused of pan-Turkism,

pan-Islamism and of contacts with "people's enemies" Kavi Nadzhmi, Shamil Usmanov, Khasan Tufan, Fatikh Saifi, Salakh Atnagulov, and Gumar Tolymbay and arrested on false charges. Thus, a stop was put to the activity of the person who possessed a broad world vision and creative thinking, who enhanced a comprehensive study of Tatar literature in the context of Russian and world literature, who realized that literature is an organism that grows in connection with living literary and aesthetic systems, who desired to study art and culture.

Thus, in the first half of the 1920s and 1930s, a new cultural-historical school was formed in the field of Tatar literary criticizm. It was based on the general principles of European and Russian cultural-historical school. E. Galiyeva writes that the works of such Tatar scholars as G. Nigmati, G. Sagdi, G. Ibragimov, Dzh. Validi, G. Rakhim, and G. Gubaidullin contain conceptual provisions of the Tatar cultural-historical school. The publications of the 1920s and 1930s were in the centre of the literary movement and dealt with Tatar literature, the history of the social-cultural movement, etc. [Galiyeva, 2002, p. 10]. The works of G. Nigmati occupy an important place among the works of famous representatives of this school. The scholar emphasized the need to synthesize different methods and techniques and offered a comprehensive model that is represented by the historical-functional method in the methodology of comparativistics and other scientific trends.

The finds and scientific research of Tatar philology of the 1920s and 1930s were cut short by great losses. Only a dozen years later, in the 1960s, the scientific heritage of G. Nigmati and other Tatar scholars was continued by Professors of Kazan University: Kh. Gosman, M. Khasanov and others. Following the traditions of the literary critics of the 1920s and 1930s, Kh. Gosman conducted the first studies in the area of the mid-20th century scientific research. The literary critic M. Khasanov explored "the forbidden topics" in Tatar literature to find out the literary and aesthetic values as well as the scientifically profound spiritual heritage of the rehabilitated Tatar writers and poets. In the late 1950s and in the early 1960s, after a change in the social and cultural conditions and with the rehabilitation of the heritage of unfairly forgotten personalities, the publication of G. Nigmati's "Selected Works", which was among the first ones, proved the value of his scientific heritage for Tatar literary criticism [Nigmati, 1958].

Galimdzhan Nigmati's philosophical and aesthetic thoughts, his research and methodological ideas are still in demand. They are relevant to the most important issues of modern times: the danger of narrowing the work of art down to the ethnic framework only, the need for a comprehensive study of the multilateral literary heritage, and the necessity of interaction of cultures and traditions for the development of artistic expression. Therefore, addressing the urgent issues of modern literary criticism and Tatar literary studies, representatives of the future generation will always turn to the heritage of the famous Tatar scholar, publicist, critic and educator, Professor Galimdzhan Nigmati, for many years to come.

**References**

*Galimdzhan Nigmäti. Ädiplärebez: bibliografik beleshmälek: 2 tomda: 2 m.* (2009) [Galimdzhan Nigmati. Our Writers: A Bibliographic Book of Reference: In Two Volumes: The Second Volume]. Töz. R. N. Dautov, R. N. Rakhmani. Pp. 197–199. Kazan: Tatar.kit.нәшр. (In Tatar)

Galiyeva, E. R. (2002). *Tatar ädäbiyat belemendä kul'tura-tarikh mäktäbe* [The Cultural-Historical School in Tatar Literary Science]. 360 p. Kazan: "Fän" näshriyaty. (In Tatar)

Gyylažev, T. (2016). *Nigmäti Galimžan. Gabdulla Tukai. Entsiklopediya. (bash mökh. Z. Z. Rämiyev)* [Nigmati G. Gabdulla Tukay. Encyclopedia. (Chief editor Z. Z. Ramiyev)]. Pp. 486–487. Kazan: G.Ibrahimov isem. Tel, ädäbiyat häm sängat' instituty. (In Tatar)

Nigmäti, G. (1925). *Ädäbiyat mäydanynda* [In the Field of Literature]. 109 p. Moscow: SSSR khalyklarynyŋ üzäk näshr. (In Tatar)

Nigmäti, G. (1929). *Revolyutsiya yellarynda ädäbiyatybyz* [Our Literature in the Years of the Revolution]. 90 p. Moscow: SSSR khalyklarynyŋ üzäk näshr. (In Tatar)

Nigmäti, G. (1931). *Ädäbiyat häm tormysh: ädäbiyat fäne mäsäläläre, tänkyyt'* [Literature and Life: Problems of Literary Science, Criticism]. 107 p. Kazan: Tatizdat. (In Tatar)

Nigmäti, G. (1934). *Tatar sovet ädäbiyaty kütäreleshtä: populyar ocherk* [Tatar Soviet Literature on the Upgrade: A Popular Essay]. 84 p. Kazan: Tatgosizdat. (In Tatar)

Nigmäti, G. (1958). *Sailanma äsärlär* [Selected Works]. Töz. Ž. Nigmätullina, Ä. Mäülikhanov. 280 p. Kazan: Tatar. kit. näshr. (In Tatar)

# ФӘНГӘ БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

**Искәндәр Энгель улы Ярмәкәев,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
ermakeev@mail.ru.

2017 елның 26 июлендә фәнни-педагогик һәм иҗади җәмәгатьчелек күренекле әдәбият галиме, публицист, тәнкыйтьче һәм педагог Галимҗан Нигъмәтинең тууына 120 ел тулуны билгеләп үтте. Кыска гына гомерендә ул татар әдәбият тарихы һәм теориясе, әдәби тәнкыйте, татарларның рухи тормышы, фәнни фикерләү үсешенә зур өлеш кертергә өлгерә, үзен күренекле җәмәгать эшлеклесе, Татарстанда әдәби процесс үсешенә җитди йогынты ясаган эзләнүчән һәм теоретик әзерлекле галим буларак таныта.

Галимҗан Нигъмәти 1897 елның 26 июлендә Уфа өязе Үдрәкбаш (Өйдерәкбаш) авылында (хәзерге Башкортстан Республикасы Чишмә районы) крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Галимҗанга ике яшь чагында, аның әтисе гаиләсе белән Уфа шәһәренә күченә.

Гади эшче булып көн күргән Әмирҗан агай, тормышы авыр булуга карамастан, улын укытырга тырыша. Башлангыч белем алган Галимҗанны Уфадагы, төрки-татар дөньясында алдынгы мәдрәсәләрнең берсе булып, шәкертләргә дини гыйлемнәр генә түгел, ә киңкырлы дөньяви белемнәр бирүе белән дә танылган "Галия"гә урнаштыра. Укыган өчен түләргә акча кирәк булгач, мәдрәсә директоры Зыя Камали тәкъдиме белән Галимҗан дәресләрдән соң өйләренә барып бай балаларын укыта башлый, ә 17-18 яшьләрендә инде ул шәкертләргә әдәбияттан дәресләр бирә.

Галимҗан Нигъмәтинең әдәби күзаллавы үсешендә 1915 елның көзеннән алып 1917 елгы Февраль инкыйлабына кадәр "Галия" мәдрәсәсендә татар әдәбиятын укыткан күренекле язучы, күпьяклы галим һәм мөгаллим Галимҗан Ибраһимов зур роль уйный. Ул үзенең педагогик эшчәнлегендә шәкертләрдә мөстәкыйль һәм иҗади фикерләү сәләте тәрбияләүгә зур игътибар итә. Мәдрәсәдә Г. Нигъмәти шигырьләр һәм пьесалар яза башлый. Әүвәл "Ай", соңрак "Парлак" исемле әдәби-иҗтимагый кулъязма журнал чыгара. Аларда Хәсән Туфан, Шәехзадә Бабич, Сәйфи Кудаш, Ченәкәй, Шамун Фидаилләр үз әсәрләрен бастыра.

"1918 елның көзеннән ул Көнчыгыш фронтның Бишенче Кызыл Армиясе сәяси бүлеге тарафыннан Уфада татар телендә нәшер ителгән "Кызыл яу" газетасында әдәби хезмәткәр вазифасын башкара. < > 1921 елны Г. Нигъмәти белем арттыру нияте белән Мәскәүгә килә, һәм Шәрык хезмәт ияләренең коммунистик университетында (КУТУВ) берьеллык курсларны тәмамлый" [Даутов, Рахмани, 2009: 197]. Биредә А. В. Луначарский, Л. Б. Красин, тарихчы М. Н. Покровский, шәркыят белгечләре А. А. Губер, И. М. Рейснер, Б. З. Шумяцкий белем бирәләр. Нигъмәти белән бергә Сафа Борһан, Ярлы Кәрим, Мәхмүт Максуд, Фатих Сәйфи-Казанлы, Нәкый Исәнбәт, Латыйф Гомәрев, Исхак Еникеев һ.б. укый. Университетта да иҗади эшчәнлеген дәвам итү максаты белән, Г. Нигъмәти Х. Ишбулатов, М. Максудлар белән берлектә әдәби түгәрәк оештырып, алар катнашында гектографик әдәби журнал чыгара башлый. Биредә шагыйрь Һади Такташның да үз әсәрләрен бастыруы мәгълүм.

1922 елның сентябрендә Г. Нигъмәти Мәскәү дәүләт журналистика институтында укый башлый, биредә шулай ук Гобәйдулла Кушаев, Шакир Рәмзи һәм киләчәктә Казанда нәшер ителәчәк газета-журналларда эшләячәк хезмәттәшләре белем ала. В. Л. Львов-Рогачевский һәм П. С. Коганның әдәбият тарихыннан, Н. К. Иванов-Грамен һәм Ф. Г. Мускатблитның публицистика теориясеннән гаять тирән эчтәлекле һәм фәнни лекцияләре аларга зур йогынты ясый һәм киләчәк гыйльми эшчәнлекләренең юнәлешләрен ачыкларга ярдәм итә.

1923 елда ВКП (б)ның Үзәк башкарма комитеты аппаратында милли матбугат буенча политбүлек оеша. Г. Нигъмәти биредә 1923 елның 15 октябреннән татар-башкорт матбугатының инструкторы вазифасын башкара. Төрекмәнстан, Кыргызстан, Татарстан, Башкортстан, Кырым һәм башка автономияле республикалардан читкә чыгучы РСФСРның татар-башкорт басмалары аның җаваплылыгында була. Нәкъ шушы чорда Г.Нигъмәти газета-журналларда гыйльми һәм публицистик мәкаләләрен бастыра башлый, ә 1925 елда әдәби күренешләрне фәнни тикшерү диапа-

зонының киңлеге, сәнгати-эстетик юнәлеше белән характерланган “Әдәбият мәйданында” дигән фәнни хезмәте дөнья күрә [Нигъмәти, 1925]. “Әдәбиятның генезисы мәсьәләсен Г. Нигъмәти үзенең иң беренче теоретик хезмәтләреннән булган “Әдәбият мәйданында” (Мәскәү, 1925) җентекле тикшереп, “әдәбиятның хезмәт процессы белән бәйләнештә туган, адәмнәрнең тормышлары, практик ихтыяҗлары белән бәйләнештә дөньяга килгән” иҗтимагыйэстетик предмет, күренеш булуын таный” [Галиева, 2002: 40].

Әдәбиятның миллилеге һәм гомумкешелек табигате кебек сыйфатларының тыгыз бәйләнешенә нигезләнгән үз стилен булдырып, Г. Нигъмәти дөнья сәнгате панорамасын өйрәнүдән милли әдәбият күренешләрен, Г. Ибраһимов, Г. Тукай, Дәрдемәнд, С. Рәмиев, Һ. Такташ иҗатларын тикшерүгә күчә.

1926 елның ноябрендә Г. Нигъмәти Казанга килә һәм республиканың үзәк газетасы “Кызыл Татарстан”, шулай ук “Яңалиф” журналының мөхәррире итеп билгеләнә. Монда ул бер үк вакытта Татар дәүләт китап нәшриятының баш мөхәррире булып эшли, Татарстан язучылары берлеген оештыру эшендә башлап йөри. 1928 елның маенда Ф. Сәйфи, Г. Толымбай, Г. Кутуй һәм К. Тинчурин белән бергә берлекнең бюро составына керә.

Нәшрият мөхәррире булып эшләгәндә, Г. Нигъмәти татар әдәбиятын өйрәнүгә һәм саклауга күп көч куя. Дәрдемәнднең сайланма әсәрләре җыентыгын бастыруда башлап йөрүчеләрнең һәм аңа кереш мәкаләне язучыларның берсе була. Иҗатка яңа килгән яшь татар язучылары һәм шагыйрьләре хакында кайгырту Г. Нигъмәти шәхесенең тагын бер үзенчәлекле һәм матур сыйфаты булып тора. Язучылар әдәби дөньясында ул, иң беренче чиратта, яңалыкка, күзаллау киңлегенә, форма-сәнгати алымнар өлкәсендә эзләнүләргә игътибар итә. 1929 елда Нигъмәти кереш мәкалә белән Хәсән Туфанның беренче шигъри җыентыгын нәшер итә. Новатор шагыйрь Һади Такташ иҗатын пропагандалый, әле киң җәмәгатьчелеккә билгеле булмаган Ибраһим Гази, Мирсәй Әмир һәм башкаларга әдәбиятсәнгать дөньясында юл табарга ярдәм итә.

Татар әдәбиятын, сүз сәнгатен гыйльми нигездә өйрәнүне әдәбият белеме алдында торган иң актуаль һәм мөһим проблемалардан санап, аны культура-тарих мәктәбе методологиясе кысаларында тикшерү тәҗрибәсе ясалган Г.Нигъмәтинең икенче фундаменталь “Әдәбият һәм тормыш: Әдәбият фәне мәсьәләләре, тәнкыйть (1931) дигән хезмәте дөнья күрә [Нигъмәти, 1931].

1929 елның көзендә Г.Нигъмәтинең тормышында һәм эшчәнлегендә тагын бер мөһим этап башлана: ул Көнчыгыш педагогика институтында (1934 елдан – Казан дәүләт педагогика институты) XX гасыр татар әдәбияты (1917 елга кадәрге әдәбият) тарихыннан лекцияләр укый башлый, 1935 елда профессор дәрәҗәсен ала.

Г.Нигъмәтинең вузга күчүе һәм педагогикметодик хезмәте әдәби-иҗади түгәрәк эшчәнлегенә яңа сулыш өрә. Биредә Сибгат Хәким әдәбият дигән олы дөньяга юл ала. Хәсән Хәйри, Мөхәммәт Гайнуллин, Хатыйп Госман, Хәмит Ярми, Афзал Кудаш һәм башка дистәләгән галим-филологларның аналитик сизгерлеге, фикри егәрлеге формалаша.

Бу елларда Галимҗан Нигъмәти үзен сәләтле галим-әдәбият белгече, татар әдәбияты тарихы һәм теориясеннән хезмәтләр авторы буларак та таныта, күренекле тәнкыйтьчеләрнең берсенә әверелә. 1917 елгы инкыйлабка кадәрге татар язучыларының (Г. Ибраһимов, Г. Тукай, М. Гафури, Дәрдемәнд һ.б.) иҗатын өйрәнү юнәлешендә нәтиҗәле эшли: “1920-1930 нчы елларда Нигъмәти шагыйрьнең фәнни биографиясен төзүгә, аны яңа фактлар белән баетуга алына. Аның тарафыннан Тукайның шигъри осталыгын үстерүдә рус һәм Европа шагыйрьләренең роле шактый калку күрсәтелә. < > шагыйрьнең иҗтимагый тирәлеккә тәнкыйди мөнәсәбәте тирәнәю, иҗатының заман чынбарлыгы белән бәйләнеше көчәю, реализм ноктасыннан яңа баскычка күтәрелү һ.б. сыйфатлары атала” [Гыйлаҗев, 2016: 486-487]. Кыска гына вакыт аралыгында ул әдәбият һәм сәнгать методологиясеннән саллы хезмәтләр язарга өлгерә; чорның каршылыклы һәм катлаулы булуына карамастан, совет язучыларының иҗаты хакында мәкаләләр циклы бастыра (К. Нәҗми, Г. Толымбай, Х. Туфан һ.б.) [Нигъмәти, 1934]. Галим үзен татар әдәбиятының гына түгел, ә рус (хәзерге һәм классик) һәм көнбатыш (классик) әдәбияты белгече буларак та күрсәтә. Л. Н. Толстой, А. М. Горький, А. П. Чехов һ.б. иҗатларына багышланган мәкаләләр яза. Аның иҗатын өйрәнүчеләр билгеләгәнчә, төрле яклап тикшереп, матур әдәбият һәм сәнгатьнең үзенчәлекләрен ачуга омтылыш Г. Нигъмәти гыйльми эшчәнлегенең характерлы сыйфаты булып тора. Шушы җаваплылык тойгысының

зур булуын исәпкә алып аны 1930 елларда Татар дәүләт академия театрының әдәби советы җитәкчесе итеп куялар.

Узган гасырның дәһшәтле, хәвефле 1930 еллар ахырында Г. Нигъмәтинең иҗаты һәм гомер юлы вакытсыз һәм фаҗигале рәвештә өзелә. Талантлы әдәбиятчы галим, принципиаль тәнкыйтьче һәм публицист, ул вакыттагы татар фәненең һәм мәдәниятенең дистәләгән күренекле вәкилләре кебек, репрессия корбаны була. “Пантюркизм һәм панисламизм”да, нахакка халык дошманнары дип тамгаланган Кави Нәҗми, Шамил Усманов, Хәсән Туфан, Фатих Сәйфи, Сәлах Атнагулов, Гомәр Толымбай һ.б. белән аралашуда гаепләнеп, төрмәгә ябыла. Фәнни һәм иҗади фикерләү киңлегенә ия булган, әдәбиятны җанлы һәм милли әдәби-эстетик системалар белән бәйләнештә үсүче организм буларак кабул итеп, татар әдәбиятын комплекслы, рус һәм дөнья әдәбияты контекстында, шулай ук сәнгать һәм мәдәниятне тулаем өйрәнүгә омтылган шәхеснең эшчәнлегенә чик куела.

1920 еллар – 1930 елларның беренче яртысында татар әдәбият белемендә гомумевропа һәм рус культура-тарих мәктәбе принципларына нигезләнеп, яңа мәдәни-тарихи мәктәп формалаша “Татар культура-тарих мәктәбенең концептуаль положенияләре Г. Нигъмәти, Г. Сәгъди, Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллиннар кебек әдәби хәрәкәтнең үзәгендә кайнаган татар галимнәренең 20-30 нчы елларда басылып чыккан, татар әдәбияты, иҗтимагый-мәдәни хәрәкәт тарихына караган күпсанлы әдәби-тарихи һәм әдәби-теоретик характерындагы хезмәтләрендә чагылыш таба” [Галиева, 2002: 10], – дип яза Э.Галиева. Алда әйтелгәнчә, әлеге мәктәпнең күренекле вәкилләре арасында Г. Нигъмәти хезмәтләре мөһим урыннарның берсен алып тора. Аларда төрле алымнарның һәм ысулларның синтезы кирәклеге ассызыкланып, тарихи-функциональ методта, компаративистика методологиясендә һ.б гыйльми юнәлешләрдә чагылыш тапкан синтезның модельләре, вариантлары тәкъдим ителә.

1920-1930 еллар татар филологиясендәге табышлар һәм гыйльми эзләнүләр зур югалтулар бәрабәренә өзелә. Бары тик дистә еллардан соң гына, 1960 елларда, Г. Нигъмәтинең һәм башка татар галимнәренең фәнни мирасы Казан университеты профессоры Х. Госман, М. Хәсәнов һ.б. тарафыннан дәвам ителә. Х. Госман 1920-1930 еллар әдәбият белеме галимнәренең тәҗрибәсен дәвам итеп, аларны XX гасыр уртасы фәнни казанышлары яссылыгында куллануда беренче тәҗрибәләр ясый. Әдәбият галиме М. Хәсәнов татар әдәбиятында “тыелган тема”ларны өйрәнүне башлап җибәреп, реабилитацияләнгән татар язучылары һәм шагыйрьләре рухи мирасларының фәнни тирәнлеген, әдәби-эстетик кыйммәтен ачарга омтыла. 1950 елларның ахыры 1960 еллар башындагы социаль һәм мәдәни шартлар үзгәрешенә җавап төсендә нахакка исемнәре һәм хезмәтләре оныттырылган шәхесләрнең мирасы кайтарыла башлагач та, беренчеләрдән булып Г. Нигъмәти “Сайланма әсәрләре” басылып чыгу аның фәнни мирасының татар әдәбияты фәне өчен кыйммәте турында сөйли [Нигъмәти, 1958].

Г. Нигъмәтинең милли кысалар белән чикләнлекнең матур әдәбият өчен хәвефлелеге, сүз сәнгатенең алгарышын тәэмин итүдә мәдәниятләр һәм традицияләр бәйләнешенең, киңкырлы әдәби мирасны комплекслы өйрәнүнең кирәклеге хакындагы гыйльми-нәзари карашлары һәм фәлсәфи-эстетик фикерләре, иҗат көчләрен һәм галимнәрне искәртеп, бүген дә актуаль яңгырый. Татар әдәбияты фәнен, тәнкыйтен өйрәнүдә һәм бүгенге әдәби барышның күп кенә актуаль проблемаларын хәл итү максатыннан киләчәк буыннар әле озак еллар дәвамында татар халкының күренекле зыялысы – галим, публицист, тәнкыйтьче һәм педагог профессор Галимҗан Нигъмәти мирасына мөрәҗәгать итәчәк.

**Әдәбият**

*Галимҗан Нигъмәти* // Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 2 т. / төз. Р.Н.Даутов, Р.Н.Рахмани. Казан: Татар.кит.нәшр.. 2009. Б. 197-199.

*Галиева Э.Р.* Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе. Казан: “Фән” нәшрияты, 2002. 360 б.

*Гыйлаҗев Т.* Нигъмәти Галимҗан // Габдулла Тукай. Энциклопедия / [баш мөх. З.З.Рәмиев]. Казан: Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. Б. 486-487.

*Нигъмәти Г.* Әдәбият мәйданында. М.: СССР халыкларының үзәк нәшр., 1925. 109 б.

*Нигъмәти Г.* Революция елларында әдәбиятыбыз. М.: СССР халыкларының үзәк нәшр., 1929. 90 б.

*Нигъмәти Г.* Әдәбият һәм тормыш: Әдәбият фәне мәсьәләләре, тәнкыйть. Казан: Татиздат, 1931. 107 б.

*Нигъмәти Г.* Татар совет әдәбияты күтәрелештә: популяр очерк. Казан: Татгосиздат, 1934. 84 б.

*Нигъмәти Г.* Сайланма әсәрләр / төз. Җ.Нигъмәтуллина, Ә.Мәүлиханов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. 280 б.